**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге составына керүче Иске Мәртле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

21 март 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Иске Мәртле авылы гражданнары җыенының 2023 елның 21 ноябрендәге 1 нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертү турында» дигән сорау буенча

«Сез Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Иске Мәртле авылы гражданнары җыенының 2023 елның 21 ноябрендәге 1 нче номерлы карарының 2 пунктына аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертүгә ризамы» соравы буенча аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

2. Алынган акчаларны түбәндәге эш төрләрен башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау);

- коймалар төзү, төзекләндерү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (зиратларны төзекләндерү);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (часовня территориясен төзекләндерү, кышкы чорда юлларны кардан чистарту).» соравын карап, 2024 елның 21 мартында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 142 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 85 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 82 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге составына керүче Иске Мәртле авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Иске Мәртле авылы гражданнары җыенының 2023 елның 21 ноябрендәге 1 нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертү турында» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Шәмәк авыл җирлеге Иске Мәртле авылы гражданнары җыенының 2023 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау);

- коймалар төзү, төзекләндерү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (зиратларны төзекләндерү);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (часовня территориясен төзекләндерү,

кышкы чорда юлларны кардан чистарту).»

4. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм  Иске Мәртле  авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Шәмәк  авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ________И.Н. Никитина

Шәмәк авыл җирлеге
башлыгы _________________ И.Н. Никитина